**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы., Үзәк урамы, 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **20 ноябрь 2023 ел** | **№80** |

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 11 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге советы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 15.10.2015 ел, № 11 карарына (Советның 27.04.2018 ел, № 111, 13.09.2018 ел, № 122, 25.12.2018 ел, № 138, 28.11.2022 ел, № 62, 14.09.2023 № 74 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

«3.2 «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мулма авыл җирлеге территориясендә мөлкәткә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Зиннәтуллин